**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«14» ноябрь, 2024ел          Теләнче Тамак авылы          № 22

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Казаклар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Советы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2024 елның 27 ноябренә 14:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Казаклар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Казаклар авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

“- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Казаклар авылы Нурми Шәрипов урамындагы су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, торбалар урнаштыру, махсус техника хезмәтләре күрсәтү)»;

«ӘЙЕ»          «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Казаклар авылы, Нурми Шарипов урамы, 40 йорт.

4. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

8. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Нәҗметдинов